РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

09.04.2026 407-п

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 23 апрелендәге 484-п номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы халкына хәбәр итү һәм мәгълүмат бирү системасы турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

2025 елның 23 июлендәге 240-ФЗ номерлы «Гражданнар оборонасы турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

**1.** Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 23 апрелендәге 484-п номерлы «Хәрби конфликтлар вакытында яисә шушы конфликтлар нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр вакытында барлыкка килә торган куркынычлар турында халыкка хәбәр итү һәм мәгълүмат бирү тәртибе турында һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы халкына хәбәр итү һәм мәгълүмат бирү системасы турындагы нигезләмәне раслау хакында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1.1.** Карарның исемендәге «Хәрби конфликтлар вакытында яисә шушы конфликтлар нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр вакытында» сүзләрен «мобилизация чорында, хәрби хәл гамәлдә булган чорда, сугыш вакытында»сүзләренә алмаштырырга.;

**1.2.** Карарның преамбуласын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

1994 елның 21 декабрендәге 68-ФЗ номерлы «Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» Федераль законга, 2012 елның 13 ноябрендәге 1522 номерлы "Гадәттән тыш хәлләр барлыкка килү яки килеп чыгу куркынычы турында халыкка экстрен хәбәр итүнең комплекслы системасын булдыру турында" Россия Федерациясе Президенты Указына, Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар зыяннарын бетерү министрлыгының һәм Россия Федерациясе Цифрлы үсеш, элемтә һәм массакүләм коммуникацияләр Министрлыгының 2020 елның 31 июлендәге 578/365 номерлы «Халыкка хәбәр итү системалары турындагы нигезләмәне раслау хакында»гы уртак боерыгы белән, Татарстан Республикасының 2004 елның 8 декабрендәге 62-ЗРТ номерлы «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында" Законы,Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 26 июлендәге 655, 610 номерлы «Татарстан Республикасы халкын үзәкләштерелгән хәбәр итүнең региональ автоматлаштырылган системасы

турындагы нигезләмәне раслау хакында» карары, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу яисә килеп чыгу куркынычы турында Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы халкына үз вакытында хәбәр итүне тәэмин итү максатларында һәм шулай ук сугыш вакытында мобилизация чорында барлыкка килә торган куркынычлар турында вакытында хәбәр итүне тәэмин итү максатында, Саба муниципаль районы Башкарма комитеты карар кабул итә:

**2.** Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 23 апрелендәге №484-п номерлы «Хәрби конфликтлар вакытында яисә шушы конфликтлар нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр вакытында барлыкка килә торган куркынычлар турында халыкка хәбәр итү һәм мәгълүмат бирү тәртибе һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы халкына хәбәр итү системасы турындагы нигезләмәне раслау турында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының гражданнар оборонасы штабы турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**2.1.** 1 нче пункттагы «хәрби конфликтлар булганда яисә шушы конфликтлар аркасында, мобилизация игълан иткәндә, хәрби хәл кертелгәндә һәм кинәт һөҗүм иткәндә» сүзләрен «мобилизация чорында, хәрби хәл гамәлдә булган чорда, сугыш вакытында»сүзләренә алмаштырырга.

**2.2.** 6 нчы пункттагы «хәрби конфликтлар булганда яисә шушы конфликтлар нәтиҗәсендә, мобилизация игълан иткәндә, хәрби хәл кертелгәндә һәм кинәт һөҗүм иткәндә» сүзләрен «мобилизация чорында, хәрби хәл гамәлдә булган чорда, сугыш вакытында»сүзләренә алмаштырырга.

**3.** Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru.рәсми порталында бастырып чыгарырга.

Башкарма комитет җитәкчесе вазифаларын башкаручы,
инвестицион үсеш комитеты һәм эшмәкәрлеккә ярдәм итү буенча
Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары -
Саба муниципаль районының инвестицион үсеш
һәм эшкуарлыкка ярдәм итү
бүлеге башлыгы И.И. Котдусов